КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 сентябрь г.Казань № 752

2019 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус һәм сөт продуктлары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан медицина оешмалары каршындагы сөт өләшү пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус һәм сөт продуктлары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус һәм сөт продуктлары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләмен.

2. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, «Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе белән берлектә, туклану өчен махсус һәм сөт продуктларын алучы өч яшькә кадәрге балаларны балаларның категорияләре, яшьләре һәм алына торган продукция төрләре буенча аерым исәпкә алуны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус һәм сөт продуктлары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2017 ел, 1 сентябрь, 625 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Премьер-министр
Республики Татарстан А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 4 сентябрь, 752 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан медицина оешмалары каршындагы сөт өләшү пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус һәм сөт продуктлары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга
норматив чыгымнар

| Балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары алучылар категориясе | Түбәндәге яшьтәге балаларга норматив чыгымнар, 1 көнгә сум | | |
|---|---|---|---|
| | 0 айдан 6 айга кадәр | 6 айдан 1 яшькә кадәр | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр |
| Җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнә торган яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар;<br>балалар туклануы өчен махсус һәм сөт продуктлары белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | 21,02 | 43,95 | 30,55 |
| ВИЧ-инфекцияле авыру аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекция белән авыручы балалар | 84,08 | - | - |

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 4 сентябрь, 752 нче
карары белән расланды

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус һәм сөт продуктлары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләме

| Балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары алучылар категориясе | Балаларның яше | Бер елга дәүләт эше күләме, бала-көн | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | адаптация-ләнгән сыек сөт катнашмасы | сөт | кефир | эремчек |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнә торган яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар; балалар туклануы өчен махсус һәм сөт продуктлары белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | 0 айдан 6 айга кадәр | 882 570 | - | - | - |
| | 6 айдан 1 яшькә кадәр | 3 098 850 | 3 098 850 | 3 098 850 | 3 098 850 |
| | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр | - | 10 937 955 | 10 937 955 | 10 937 955 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| ВИЧ-инфекцияле авыру аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекция белән авыручы балалар | от 0 до 6 ме-сяцев | 24 455 | - | - | - |

---